КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1030

Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядтагы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^3$ статьясындагы 7 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау турында» 2016 елның 23 декабрендәге 1452 номерлы карары белән расланган Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау кагыйдәләренең $22^1$ нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Төзелешнең смета кыйммәтен билгеләү максатлары өчен Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядтагы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләмен 2019 елга 20 976,0 сумга тигез итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядтагы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында» 2019 ел, 25 декабрь, 1199 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин